СОВЕТ КЕМЕШ-КУЛЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д.61, с. Кемеш-Куль,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422147

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КӨМЕШ-КҮЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Үзәк ур., 61 нче йорт, Көмеш-Күл авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422147

тел.(факс): (85563) 2-46-38; e-mail: KemKul.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

№2-37 от 21.03.2019 г.

Решение Карар

Законнардагы үзгәрешләргә һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актларына мониторинг үткәрү турындагы Нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән (чыгарылган) муниципаль норматив хокукый актларга мониторинг үткәрү буенча Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге җирле үзидарә органнары эшен камилләштерү максатларында, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актларына мониторинг үткәрү турында Нигезләмәне расларга (кушымта).

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актларына мониторинг үткәрү буенча җаваплы зат итеп Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге Башлыгы И.П. Крешковны билгеләргә.

3. Әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге башлыгы И.Н.Сәләхетдиновка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Көмеш-Күл авыл җирлеге башлыгы,
Совет председателе Сәләхетдинов И.Н.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге Советының 21.03.2019 ел, 2-37 нче санлы карарына кушымта

## Законнардагы үзгәрешләргә һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актларына мониторинг үткәрү турында Нигезләмә

### I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү мониторингы (Алга таба – мониторинг, муниципаль актлар, җирле үзидарә органнары) җирле үзидарә органнары тарафыннан үз вәкаләтләре чикләрендә гамәлгә ашырыла торган системалы, комплексны һәм план эшчәнлеген, мәгълүмат кабул итүне (бастыруны) тәэмин итү, муниципаль актларны үзгәртү һәм аларның көчен югалтуын тану өчен җыю, анализлау һәм бәяләү эшчәнлеген күздә тота.

2. Мониторинг Көмеш-Күл авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан үткәрелә.

3. Көмеш-Күл авыл җирлеге җирле үзидарә органннары мониторинг үткәргәндә Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты юридик бүлеге белән хезмәттәшлек итәләр.

4. Көмеш-Күл авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында мониторинг үткәрү өчен җаваплы затлар билгеләнә.

5. Мониторинг үткәрүнең максатлары булып түбәндәгеләр торалар:
федераль һәм республика законнарына туры китерү максатларында муниципаль актларны кабул итү, үзгәртү һәм аларның үз көчләрен югалтуын тану ихтыяҗларын ачыклау;
муниципаль актларда каршылыкларны, кимчелекләрне, хокукый җайга салуда кабатлауларны бетерү;
җирле үзидарә органнарының норматив хокукый базасын системалаштыруны тәэмин итү;
муниципаль актларда коррупциячел факторларны ачыклау;
муниципаль актларның яисә аларның аерым нигезләмәләренең (нормаларның) гамәлдә файдаланмаган (актуальлеген югалткан) яисә алмаштырылмаган нигезләмәләрен ачыклау;
хокук куллану нәтиҗәлелеген арттыру; муниципаль актларны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген киметүче факторларны ачыклау;
муниципаль актларның үтәлешенә җирле үзидарә органнарының тиешле бүлекчәләре тарафыннан контрольне гамәлгә ашыруга булышлык күрсәтү;
нормалар чыгару процессын камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләү.

6.Мониторинг үз эченә түбәндәге документлардагы үзгәрешләр буенча җыю, гомумиләштерү, анализлау һәм бәяләүне үз эченә ала:
федераль конституциячел законнар, федераль законнар, Россия Федерациясенең башка закон актлары;
Россия Федерациясе Президенты указлары, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары, федераль башкарма хакимият органнарының норматив хокукый

актлары, федераль дәрәҗәдәге башка законга кагылышлы норматив хокукый актлар;

Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары;

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге Уставы, муниципаль актлар.

7. Мониторинг үткәрүнең нигезләре булып түбәндәгеләр тора:

федераль һәм республика законнары актларына үзгәрешләр кертү;

хокукый җайга салу өлкәсендә муниципаль актларны куллануны анализлау;

прокуратура органнары мәгълүматы;

муниципаль актларны камилләштерү яки кимчелекләре турында массакүләм мәгълүмат чаралары мәгълүматы;

гражданнарның, юридик затларның, шул исәптән иҗтимагый, фәнни, хокук саклау һәм башка оешмаларның, шәхси эшкуарларның, дәүләт хакимияте органнарының, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларының муниципаль актларның камил булмавы турында мөрәҗәгатьләре, шул исәптән үз эченә түбәндәгеләрне алган мөрәҗәгатьләр:

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертелгән муниципаль актларга карата үткәрелгән Хокукый экспертиза бәяләмәсе;

билгеләнгән тәртиптә вәкаләтле затлар тарафыннан әзерләнгән муниципаль актларга коррупциягә каршы экспертиза бәяләмәләре;

җирле үзидарә органнары үткәрә торган конференцияләрнең, семинарларның, гавами тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышуларның һәм башка чараларның йомгаклау документлары.

## II.Мониторингны үткәрү тәртибе

8. Көмеш-Күл авыл җирлеге җирле үзидарә органнары әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында күрсәтелгән җаваплы затлар белән үзара бәйләнешлелек аларның компетенциясе мәсьәләләре буенча мониторинг үткәрәләр.

9. Мониторинг анализ аша башкарыла:

әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында күрсәтелгән актлар;

федераль, республика һәм муниципаль дәрәҗәдәге норматив хокукый актларны дәгъвалау эшләре буенча суд актлары (суд практикасы) ;

прокурор актлары.

10. Мониторингны гамәлгә ашыру, җирле үзидарә органнарының норматив базасын анализлау, шулай ук мониторинг йомгаклары буенча үткәрелгән нормалар иҗат итү эше нәтиҗәләрен фиксацияләү максатларында муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын оештыру һәм алып бару тәртибе турында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары нигезендә башкарыла торган муниципаль норматив хокукый актлар реестрлары файдаланыла.

11.Мониторингны гамәлгә ашыру процессын оптимизацияләү өчен мәгълүмат системаларының автоматлаштырылган сервислары кулланыла (контрактлар, аларның операторлары белән килешүләр төзүгә бәйле күрсәтелгән мөмкинлекләр булганда):

"Гарант" мәгълүмат системасында закон һәм башка норматив хокукый актларга контрольга куелган үзгәрешләр турында мәгълүмат керү;

Гарант мәгълүмат системасын хокукый җайга салуның тиешле өлкәләре буенча яңалыклар тасмалары мәгълүматы керү;

«Кодекс» мәгълүмат компаниясенең «Төбәк законнары аналитигы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасы муниципаль актларның законнарга туры килмәве турында мәгълүмат керү.
Мониторингны гамәлгә ашыру процессын оптимальләштерү максатларында башка мәгълүмат системалары сервислары файдаланыла ала.

12.Муниципаль хокукый актларны кабул итүне (бастырып чыгаруны) тәэмин итү, үзгәртү яки үз көчен югалткан дип тану (гамәлдән чыгару) мониторингын гамәлгә ашырганда әлеге Нигезләмәнең 9 пунктында күрсәтелгән анализ белән беррәттән муниципаль актларны түбәндәге критерийлар буенча куллану практикасы турында мәгълүмат гомумиләштерелә һәм бәяләнә:
гражданнарның гарантияләнгән хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү;
муниципаль актларны кабул итү (бастырып чыгару) зарурлыгы билгеләнгән югарырак юридик көчкә ия норматив хокукый актлар булу;
муниципаль акт чыгарганда җирле үзидарә органы компетенциясенең чикләрен саклау;
муниципаль актта коррупциячел факторлар булу;
иҗтимагый мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салудагы тулылык;
хокук нормаларындагы каршылыклар;
юридик-техник характердагы хаталар булу;
муниципаль акт нигезләмәләрен кулланганда аларның мәгънәсен бозу;
муниципаль хокукый актны кулланганда хокуксыз яисә нигезсез карарлар, гамәлләр (гамәл кылмау) кабул итү;
норматив хокукый актларны куллану тәҗрибәсе булу;
норматив хокукый актларны куллануның бертөрле практикасы булмау;
муниципаль актны аңлату мәсьәләләре буенча гаризаларның эчтәлеге һәм (саны) булу ;
муниципаль акт белән җайга салынган мөнәсәбәтләргә бәйле рәвештә мөрәҗәгать итүчеләрнең таләпләрен канәгатьләндерү (канәгатьләндерүдән баш тарту) турындагы закон көченә кергән суд актлары һәм аларны кабул итүнең нигезле булуы (саны).

13.Федераль һәм республика законнарына үзгәрешләр мониторингы нәтиҗәләре буенча җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль актларга, үзгәрешләр кертү кирәклеге ачыкланган очракта:
муниципаль актка үзгәрешләр кертү , муниципаль актның үз көчен югалтуын тану, яңа муниципаль акт кабул итү турында муниципаль акт проектлары эшләнә;
муниципаль актларны югарырак юридик көч актлары белән тәңгәлләштерүгә юнәлдерелгән башка чаралар күрелә.

14.Муниципаль актларны үзгәртү ихтыяҗы тудыручы федераль һәм республика законнары актларына үзгәрешләр кертелгән очракта, мониторинг федераль яки республика актын чыгарганнан соң 30 көн эчендә үткәрелә.
Мониторинг үткәрүгә нигез булып гражданнарның, юридик затларның, шәхси эшкуарларның, дәүләт хакимияте органнарының, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларының мөрәҗәгатьләре торса, шулай ук прокуратура мәгълүматы, прокурор җавабы актларыннан тыш, мониторинг «Россия Федерациясе прокуратурасы турында» Федераль закон белән билгеләнгән срокларда карала торган карарлардан тыш, 30 көн эчендә гамәлгә ашырыла. Күрсәтелгән очракларда мониторинг үткәрү нәтиҗәләре турында мөрәҗәгать итүче затка хәбәр ителә.

Федераль һәм республика законнары актларының ерак перспективада үз көченә керә торган үзгәрешләре ачыкланган очракта, җирле үзидарә органнарының

норма чыгару эшчәнлеге планнарына тиешле төзәтмәләр кертү турында тәкъдимнәр кертелә.

## III.Мониторинг нәтиҗәләрен гамәлгә ашыру

15.Муниципаль акт проектын эшләү һәм мониторинг нәтиҗәләре буенча муниципаль акт кабул итү, әлеге нигезләмәнең 14 пунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән очрактан тыш, федераль һәм (яисә) республика законнарының тиешле акты үзгәртелгән вакыттан ике ай эчендәбашкарыла.

16.Мониторинг үткәрү өчен җаваплы затлар җирле үзидарә органнары җитәкчеләре алдында хисаптан соң килүче айның 5 числосыннан да соңга калмыйча мониторинг нәтиҗәләре турында хисап тота.

16.1.Мониторинг нәтиҗәләре буенча хисапта (мәгълүмат) түбәндәгеләр булырга тиеш:

мониторинг үткәрү объекты турында мәгълүмат;

мониторинг үткәрүне башкаручылар турында мәгълүмат;

мониторинг үткәрү вакыты турында мәгълүмат;

хокукый җайга салу предметының кыскача характеристикасы, мониторинг үткәрү нигезләре.

16.2.Мониторинг нәтиҗәләре буенча хисапта (мәгълүмат) түбәндәгеләр булырга мөмкин:

хокукый җайга салуның ачыкланган проблемалары турында мәгълүмат;

муниципаль актларга үзгәрешләр кертү һәм (яки) яңа муниципаль актларны кабул итү, юкка чыгару зарурлыгы турында тәкъдимнәр;

тиешле хокукый мөнәсәбәтләр өлкәсендә хокукый җайга салуны камилләштерүгә юнәлдерелгән мониторинг нәтиҗәләренә нигезләнгән башка нәтиҗәләр һәм тәкъдимнәр.

17. Мониторинг нәтиҗәләре буенча кабат кабул ителгән муниципаль актлар Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына законнар белән билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда кертү өчен җибәрелә.

Әлеге регистрга кертү өчен мониторинг нәтиҗәләре буенча ачыкланган анда булмаган муниципаль актлар җибәрелә.

18. Мониторинг нәтиҗәләре буенча норма чыгару процессын камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләнергә мөмкин.

## IV. Җаваплылык

19.Мониторинг үткәрү һәм хокукый иҗат итү эшчәнлеге өчен җаваплы затлар мониторингны оештыру өчен шәхси (шул исәптән дисциплинар) җаваплылык тоталар, шулай ук муниципаль актларны җирле үзидарә органнары карамагына караган хокукый җайга салу өлкәсендә федераль һәм республика законнарына туры китерү вакытында башкарыла торган эшләр өчен.

20.Тискәре нәтиҗәләргә, шул исәптән гражданнарга, юридик затларга, җәмгыятькә һәм дәүләткә зыян китергән мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлләр (гамәл кылмау) өчен законнар нигезендә җирле үзидарә органнары җитәкчеләре җавап тоталар.